**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**19.06.2023 ел** **№93**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында» 2014 елның 28 февралендәге 90 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегенең 2014 елның 28 февралендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 19 статьясындагы 3 өлешенә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Раиса) сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет рәисе Танчук Н.В.